**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 10 февраль № 77

г. Казань

Дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу хакында

«Саескан Тавы – Шәле» автомобиль юлын төзү һәм реконструкцияләү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының 49, 55 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Юл-транспорт комплексын карап тору һәм үстерү буенча баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең Лаеш муниципаль районында урнашкан, Р.З.Шәрәпов милкендә булган 19,567 гектар мәйданлы авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге 16:24:040201:96 кадастр санлы җир кишәрлеген (алга таба – җир кишәрлеге) сатып алу юлы белән алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

җир кишәрлеген сатып алу бәясен билгеләүне һәм аның милекчесе белән тиешле килешү төзүне;

җир кишәрлеген тиздән алыначагы турында милекчегә хәбәр итүне;

бу карарны дәүләт теркәвенә алуны һәм теркәү үткәрелү турында, аны теркәү датасын күрсәтеп, җир кишәрлеге милекчесенә хәбәр итүне;

милекче җир кишәрлеген алу турындагы карар белән килешмәгән очракта, судка тиешле дәгъвалар кертүне;

сатып алынган җир кишәрлегенә Татарстан Республикасы милке хокукын дәүләт теркәвенә алу үткәрүне.

3. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына җир кишәрлегенең сатып алу бәясен билгеләгәннән соң Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җир кишәрлеген Татарстан Республикасы милкенә сатып алу чыгымнарын финанслау күләмнәре һәм чыганаклары турында тәкъдимнәр кертергә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\77.doc